# 4 САНЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

30 ноябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Чыпчык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 28 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта, 2021 елның 29 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2021 елның 30 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта уздырылган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыелган гражданнарның үзара салым акчаларын сату нәтиҗәләре буенча экономияләү хисабына калган контейнер мәйданчыкларын урнаштыруга, киләсе эш төренә: Чыпчык авылы эчендәге юлларны вак ташлауга Сез килешәсезме?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1248 (Бер мең ике йөз кырык сигез) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 648 (Алты йөз кырык сигез) кеше, бу 52%ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде: “Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 648 (Алты йөз кырык сигез) катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (Ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Чыпчык авыл җирлегендә халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танылды.

2. "2020 елгы халык җыены нәтиҗәләре буенча җыелган гражданнарның үзара салым акчаларын сату нәтиҗәләре буенча экономия ясау хисабына калган контейнер мәйданчыкларын урнаштыруга яңача бүлүгә килешәсезме?" дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булган очракта Чыпчык авыл җирлеге Башкарма комитетына акчаларны, җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Чыпчык авыл җирлеге Советы
Совет Чепчуговского сельского поселения
ИНН 1616004928

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чыпчык авыл җирлеге башлыгы И.Р.Җиһаншин